РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Макаровского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423568, Нижнекамский район,
с. Верхняя Уратьма ул. Молодежная, 2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Макаровкаавыл жирлеге
Советы

423568, Түбән Кама районы, Югары
Уратма авылы, Яшьлер урамы, 2

тел./факс (8555) 33-21-44, электронный адрес: sp.makarovskoe@tatar.ru, сайт: www.makarovskoe-sp.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2020 ел № 3

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
«Макаровка авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлеге Уставына
Үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципальрайонының «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Макаровка уавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Макаровка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң,әлеге карарны халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар законнарда каралган тәртиптә үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ОГРН 1031619002690 «СОВЕТ МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ» ИНН 1630003161

Т.К. Ладнушкина

Макаровка авыл җирлеге
Советының
2020 елның 21 февралендәге
3 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

1. «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясының 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 20 пунктча өстәргә:

«20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә,җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, федераль законнарда билгеләнгән территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән билгеләнгән үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү карары, үз белдеге белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектын үзгәртеп коруның иң чик параметрларына туры китерү карары кабул итү.».

2. «Гражданнар җыены» 15.1 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган очракларда, гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

- әлегеторак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерә торган күрсәтелгән торак пункт аның составына кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча торак пунктта;

- Җирлек составына керүче торак пункта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча;

- авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл торак пункты старостасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча.

2. Авыл торак пунктында гражданнар җыены, шулай ук муниципаль хезмәттурында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә, конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин.

3. Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Торак пункта берүк вакытта әлеге торак пункта яшәүчеләрнең яртысыннан артык сайлау хокукына ия булган гражданнарының бергә буллу мөмкинлеге булмаса, җирлек уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан да артмаган срокта уздырылырга тиеш. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, мондый җыенның карары кабул ителгән дип санала.

4. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе җирлекнең торак пунктларында халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән раслана.».

3.«Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты статусы» 28 статьясында:

а) 8 пунктны «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә;

б) 11 пунктта «Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка мөрәҗәгать итә.» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы,җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында яки күрсәтелгән затларга карата бүтән җаваплылык чарасын куллану турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка мөрәҗәгать итә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 11.1 пунктын өстәргә: «11.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес һәм тулы булмаган мәгълүматлар биргән җирле үзидарә депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, аның вәкаләтләре вакыты беткәнче, җирлек Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итеп, Җирлек Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән азат итү;

3) аның вәкаләтләре срогы беткәнче даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп,даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) Җирлек Советында, Җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы, даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 11.2 пунктын өстәргә «11.2. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына каратаТатарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән, әлеге статьяның 11.1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе.».

4. «Җирлек Советы компетенциясе» 31 статьясында 32 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

5. «Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 38 статьясында 1 өлешнең 8 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

6. «Җирлек башлыгы статусы» 41 статьясында:
а) 3 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:
«3. Җирлек башлыгы хокуклы түгел:
1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;
2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:
а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы идарәсендә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашу;
б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы идарәсендә түләүсез нигездә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы Премьер-министрына) алдан белдереп, түләүсез нигездә катнашу;
в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;
г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, муниципаль берәмлек гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;
д) федераль законнарда каралган башка очраклар;
3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары, чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларның башка органнары һәм Россия Федерациясе территориясендә эш итүче аларның структур бүлекчәләр есоставына керергә.

Даими нигездә вәкаләтләрен башкаручы депутат граждан, административ яки җинаять эше буенча яисә административ хокук бозу эше буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) буларак катнаша алмый.

Җирлек Советы депутатларының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре әлеге Устав беләнфедеральзаконнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.»;

б) 4 һәм 7 өлешләрен үз көчен югалткан дипт аныргa.

7. «Авыл җирлеге башлыгы урынбасары» 43 статьясында «40 статьясы» сүзләрен «41 статьясы» сүзләренә алмаштырырга.

8. «Башкарма комитет вәкаләтләре» 47 статьясында:

а) 1 өлешнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: « - Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, федераль законнарда билгеләнгән территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән билгеләнгән үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү карары, үз белдеге белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектын үзгәртеп коруның иң чик параметрларына туры китерү карары кабул итә.»;

б) 1 өлешнең 6 пунктындагы 10 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

9. «Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе» 68 статьясында 1 өлешнең беренче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Җирлек Советы карарлары, әгәр башкасы карарның үзе белән билгеләнмәгән булса, Җирлек башлыгы имзалаган көннән соң 10 көн узгач, үз көченә керә.».

10. «Җирлек бюджеты» 74 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә: «5. Җирлектә бюджет процессын хокукый җайга салу Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, җирлек Советы карары һәм башка муниципаль хокукый актлар белән расланган җирлекнең бюджет төзелеше һәм бюджет сәясәте турындагы нигезләмә белән гамәлгә ашырыла.».

11. 75-81 статьяларын үз көчен югалткан дип танырга.